Аксубаймуниципаль районы Яңа Кармәтавылжирлеге Советы
423060Аксубай районы,Яңа Кармәт авылы,
Муса Җәлил урамы, 15а нче йорт

Совет Новокиреметского сельского поселения Аксубаевского муниципального района
423060Аксубаевский район,с.Новая Киреметь, улица Мусы Джалиля, д.15а

Тел. (8-84344-4-92-33) ОГРН 1021605359709,
ОКПО 04311599, ИНН/КПП 1603001197/160301001
E-mail*: Nkir..Aks@tatar.ru,*

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Яңа Кармәт авыл җирлеге башлыгы

КАРАР

№6 2022 елның 1нче ноябре

**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы " Яңа Кармәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планы проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 23, 24, 25 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль закон, Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлеге Уставы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлеге Советының «Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлеге территориясендә халык алдында тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 27 апрелендәге 63 номерлы карары ( алга таба-карар) нигезендә Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлегендә яшәүчеләрнең проект турында фикер алышуда катнашу хокукларын үтәү максатларында ачык тыңлаулар үткәрү юлы белән **КАРАР БИРӘМ:**

1. Аксубай муниципаль районының «Яңа Кармәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планы проектын ( алга таба–Генераль план проекты) гавами тыңлауларга чыгарырга.

2. Татарстан Республикасы, Аксуба ймуниципаль районы, Яңа Кармәт авылы, Муса Җәлил урамы, 15а нче йорт адресы буенча мәгълүмат стендына элү юлы белән халыкка хәбәр итәргә – ачык тыңлаулар үткәрү турында хәбәр; - Аксубай муниципаль районы «Яңа Кармәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль план проекты буенча гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм аның турында фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибе (1 нче кушымта); - Аксубай муниципаль районының «Яңа Кармәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль план проекты (3 нче кушымта).

3. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы «Яңа Кармәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль план проекты буенча 2022 елның 2 декабрендә 14 сәгатьтә Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында (адресы: Татарстан Республикасы, Аксубай муниципаль районы, Яңа Кармәт авылы, Муса Җәлилурамы, 15а нче йорт) ачык тыңлаулар билгеләргә
4. 2 нче кушымта нигезендә кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча эшче төркем төзергә.

5.Эшче төркем:
- билгеләнгән тәртип һәм әлеге карар белән билгеләнгән сроклар нигезендә Генераль план проекты буенча ачык тыңлаулар әзерләргә һәм үткәрергә;
- ачык тыңлаулар үткәрү нәтиҗәләре буенча ачык тыңлаулар беркетмәсен, ачык тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә, шулай ук Генераль план проектына өстәмәләр ( үзгәрешләр кертелгән очракта) әзерләргә;
- 2022 елның 6 декабренә кадәр ачык тыңлауларның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендында һәм Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

6. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында веб-адрес http://pravo.tatarstan.ru буенча урнаштырырга:.

7.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Яңа Кармәт авыл җирлеге башлыгы: СОВЕТ НОВОКИРЕМЕТСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ И.Р.Шакиров

Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлеге башлыгының №6 01.11.2022 карарына 1 нче кушымта

Ачык тыңлаулар үткәрү
ТӘРТИБЕ

1. Ачык тыңлауларда катнашу өчен гаризалар ТР Аксубай районы Яңа Кармәт авылы, Муса Җәлил урамы, 15а нче йорт адресы буенча, шәхсән яки почта аша тапшырыла

2. Ачык тыңлауларда катнашучылар, үз тәкъдимнәрен дәлилләү өчен чыгыш ясау хокукы белән, халык алдында тыңлаулар үткәрү датасына кадәр язмача гаризалар биргән җирлек халкы катнаша.

3. Халык тыңлауларында чыгыш ясау хокукыннан башка, җирлекнең барлык кызыксынган кешеләре катнаша ала.

4. Катнашучыларны теркәү ачык тыңлаулар башланганчы 30 минуттан башлана.

5. Халык алдында тыңлауларда җирлек башлыгы рәислек итә. Халык алдында тыңлаулар рәислек итүченең кереш сүзе белән ачыла, ул утырышта катнашучыларга фикер алышына торган мәсьәләнең асылы, тыңлауларны үткәрү тәртибе турында хәбәр итә.

6. Ачык тыңлауларда катнашучылар, гариза бирү вакытына карап, чират тәртибендә үз тәкъдимнәрен дәлилләү өчен чакырыла.

7. Ачык тыңлауларда катнашучыларның чыгышлары 5 минуттан артык дәвам итәргә тиеш түгел.

8. Ачык тыңлауларда катнашучылар чыгыш ясаганнан соң чыгыш ясаучыларга рәислек итүче рөхсәте белән сораулар бирергә хокуклы.

9. Халык тыңлауларында катнашучылар ачык тыңлаулар барышына тыкшынырга, аларны өзәргә һәм үткәрүгә комачауларга хокуклы түгел.

10. Ачык тыңлауларда катнашучылар тарафыннан уздыру тәртибе бозылган очракта, рәислек итүче аларны утырыш залыннан чыгаруны таләп итәргә хокуклы.

11. Ачык тыңлауларда катнашучыларның барлык кисәтүләре һәм тәкъдимнәре гавами тыңлаулар беркетмәсенә кертелә. Беркетмә җирлек советы материалларында билгеләнгән тәртиптә саклана.

12. Ачык тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә эшче төркем тарафыннан әзерләнә һәм бастырып чыгарылырга тиеш.

Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлеге башлыгының №6 01.11.2022 карарына 2 нче кушымта

**Исәпкә алу, кергән тәкъдимнәрне гомумиләштерү һәм карау буенча эшче төркем составы**

| | |
|---|---|
| Шакиров И.Р. | - комиссия председателе, Яңа Кармәт авыл җирлеге башлыгы |
| Ислямов И.И. | - Аксубай муниципаль районы инфраструктура үсеше (килешү буенча) буенча Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары |
| Габдрахманов М.А. | - Аксубай муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе (килешү буенча)) |
| Сахабутдинова Л.С. | – ТР буенча Росреестр Идарәсенең Аксубай, Яңа Чишмә һәм Чирмешән районнары буенча муниципальара бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Хусаенова Г. Р. | - Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлеге Башкарма комитет җитәкчесесе урынбасары, комиссия секретаре. |

Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлеге башлыгының №6 01.11.2022 карарына 3 нче кушымта

**Карар проекты**

**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының " Яңа Кармәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планын раслау турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 24 статьясына, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Яңа Кармәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып һәм «Яңа Кармәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планы проекты буенча фикер алышу нәтиҗәләрен карап, Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлеге Советы Карар:

1.Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Яңа Кармәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең «Татарстан Республикасы пространство мәгълүматлары фонды» ДБУ тарафыннан эшләнгән Генераль планын расларга (1 нче кушымта).

2. «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Яңа Кармәт авыл җирлеге Генераль планын раслау турында» 2012 елның 18 декабрендәге 12 номерлы карары үз көчен югалткан дип санарга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) вакыттан үз көченә керә .

4.Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында веб-адрес http://pravo.tatarstan.ru буенчаурнаштырырга:

5. Әлеге карарныңүтәлешенконтрольдәтотам.

ТР Аксубай муниципаль районы
Яңа Кармәт авыл җирлеге
Советы председателе И.Р.Шакиров

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ "АКСУБАЕВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН" ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
Р 06-650/13
СОВЕТ НОВОКИРЕМЕТСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1603001197 ОГРН 1021605359700